КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 сентябрь г.Казань № 1027

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2019 ел, 11 июль, 565 нче; 2019 ел, 28 август, 714 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1278 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 21 май, 413 нче, 2020 ел, 1 сентябрь, 772 нче; 2020 ел, 23 октябрь, 954 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 821 нче; 2021 ел, 29 октябрь, 1021 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 15 июнь, 566 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең база окладларын билгеләү

1. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Әйдаман | 15 279 | - | - |
| | Тәрбияче ярдәмчесе | | - | - |
| | Уку-укыту эшләре бүлеге секретаре | | 15 552 | - |
| Икенче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Режим буенча кизү торучы | - | 15 662 | 15 672 |
| | Кече тәрбияче | 15 362 | | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү оешмасы диспетчеры | - | 15 862 | 15 872 |
| | Режим буенча өлкән кизү торучы | | | |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт буенча инструктор | - | 16 142 | 18 362 |
| | Физик культура буенча инструктор | | | |
| | Музыка җитәкчесе | | | |
| | Өлкән әйдаман | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Концертмейстер | - | 16 149 | 18 382 |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | | | |
| | Оештыручы педагог | | | |
| | Социаль педагог | | | |
| | Мөгаллим тренер | | | |
| | Инструктор-методист | - | - | 18 382 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | - | 16 155 | 18 394 |
| | Производство белеме бирү мастеры | | | |
| | Педагог-психолог | | | |
| | Өлкән инструктор-методист | - | - | |
| | Өстәмә белем бирү буенча өлкән педагог | - | - | |
| | Өлкән мөгаллим тренер | - | - | |
| | Методист | - | - | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Мөгаллим (профессорлар һәм мөгаллимнәр составына кертелгән мөгаллимнәр вазифаларыннан башка) | - | 16 157 | 18 398 |
| | Тормыш иминлеге нигезләре буенча оештыручы мөгаллим | | | |
| | Физик тәрбия җитәкчесе | | | |
| | Укытучы | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | Өлкән тәрбияче | - | - | |
| | Өлкән методист | - | - | |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | - | - | |
| | Укытучы-дефектолог | - | - | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | - | - | |
| | Педагог-китапханәче | - | - | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе, гомуми белем бирү программасы һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программасы тормышка ашырыла торган башка структур бүлекчәләр, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләре тормышка | - | - | 18 463 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | ашырыла торган оешма мөдире (башлыгы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан башка) | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү программасы һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программасы тормышка ашырыла торган аерымланган структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы), кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе, уку хуҗалыгы һәм башкалар башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) | - | - | 18 526 |

2. Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Аккомпаниатор | 16 388 | 16 899 | 17 199 |
| Мәдәни чаралар оештыручы | | | |
| «Төп звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Китапханәче | 16 388 | 17 399 | 19 899 |
| Тавыш операторы | | | |
| Төп китапханәче | | | |
| Рәссам-декоратор | | | |
| Баш китапханәче | | | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Китапханә бүлеге (секторы) мөдире | - | 18 599 | 21 199 |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | | | |

3. Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | 1 айга база окладлары күләме, сум |
|---|---|---|
| «Беренче дәрәҗә медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы | 15 279 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 16 200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Диета буенча шәфкать туташы | 16 700 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 17 200 |
| | Физиотерапия буенча шәфкать туташы | |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Фельдшер | 17 900 |
| | Процедура бүлмәсенең шәфкать туташы | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы | 18 900 |
| | Сәламәтлек саклау пункты мөдире – фельдшер (шәфкать туташы) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 20 600 |

4. Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлегендә яки һөнәри стандартларда билгеләнгән дәрәҗәдән белеме түбән булган хезмәткәрләр вазифага алынган очракта, мондый хезмәткәрләргә база окладлары таләп ителә торган белем дәрәҗәсенә карап билгеләнә.

5. Хезмәткәрләрнең белем дәрәҗәсе Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлегендә яки һөнәри стандартларда билгеләнгән дәрәҗәдән югарырак булса, мондый хезмәткәрләргә база окладлары таләп ителә торган белем дәрәҗәсенә карап билгеләнә.»;

16 нчы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 нчы таблица

Гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренең база окладлары
һәм стимул бирү характерындагы түләүләр күләмнәре

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Күләм күрсәткеченең зурлыгы (уку елы башына карата укучылар, тәрбияләнүчеләр саны), кеше* | База оклады, сум | Стимул бирү характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 – 15 | 25 000 | 3 000 |
| 2 | 16 – 50 | 27 000 | 3 000 |
| 3 | 51 – 100 | 31 000 | 4 000 |
| 4 | 101 – 200 | 32 000 | 6 000 |
| 5 | 201 – 400 | 35 000 | 9 000 |
| 6 | 401 – 600 | 37 000 | 9 000 |
| 7 | 601 – 800 | 40 000 | 9 000 |
| 8 | 801 – 1 000 | 43 000 | 9 000 |
| 9 | 1 001 – 1 200 | 44 000 | 11 000 |
| 10 | 1 201 – 1 400 | 45 000 | 12 000 |
| 11 | 1 401 – 1 800 | 45 000 | 15 000 |
| 12 | 1 801 һәм аннан да югарырак | 46 000 | 18 000 |

*Девиант тәртипле укучылар өчен ябык типтагы гомуми белем бирү оешмалары, җинаять-үтәтү системасының төзәтү учреждениеләре каршындагы гомуми белем бирү оешмалары, озак дәвалануга мохтаҗ балалар өчен шифаханә тибындагы гомуми белем бирү оешмалары, җайлаштырылган уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү оешмалары укучылары контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда яшәүче укучылар контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына.

Гомуми белем бирү оешмаларының мәктәпкәчә төркемнәрендә тәрбияләнүчеләр контингенты 1,5 коэффициенты белән исәпкә алына.

Мәктәпара уку-укыту комбинатларында укучылар контингенты 0,5 коэффициенты белән исәпкә алына»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең база окладларын билгеләү

1. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Әйдаман | 15 279 | - | - |
| | Тәрбияче ярдәмчесе | | - | - |
| Икенче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кече тәрбияче | 15 362 | 15 662 | - |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | - | 16 142 | 18 362 |
| | Музыка җитәкчесе | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә белем бирү педагогы | - | 16 149 | 18 382 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | - | 16 155 | 18 394 |
| | Педагог-психолог | - | | |
| | Методист | - | - | |
| Дүртенче квалифика-ция дәрәҗәсе | Өлкән тәрбияче | - | - | 18 398 |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьюторлардан тыш) | | | |
| | Укытучы-дефектолог | | | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: кабинеты, лабораториясе, бүлеге, бүлекчәсе, секторы, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе, гомуми белем бирү программасы һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программасы тормышка ашырыла торган башка структур бүлекчәләре, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати | - | - | 18 463 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләре тормышка ашырыла торган оешма мөдире (башлыгы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан башка) | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү программасы һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программасы тормышка ашырыла торган аерымланган структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы), башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе (бүлекчәсе) кабинеты, лабораториясе, бүлеге, бүлекчәсе, секторы, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (укыту-җитештерү) | - | - | 18 526 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | остаханәсе, укыту хуҗалыгы һәм башка структур бүлекчәләре башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) (өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан башка) | | | |

2. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| «Беренче дәрәҗә медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы | 15 279 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Дәвалау физкультурасы буенча инструктор | 16 200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Диета буенча шәфкать туташы | 16 700 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 17 200 |
| | Физиотерапия буенча шәфкать туташы | |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Фельдшер | 17 900 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы | 18 900 |
| | Сәламәтлек саклау пункты мөдире – фельдшер (шәфкать туташы) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 20 600 |

3. Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлегендә яки һөнәри стандартларда билгеләнгән дәрәҗәдән белеме түбән булган хезмәткәрләр вазифага алынган очракта, мондый хезмәткәрләргә база окладлы таләп ителә торган белем дәрәҗәсенә карап билгеләнә.

4. Хезмәткәрләрнең белем дәрәҗәсе Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлегендә яки һөнәри стандартларда билгеләнгән дәрәҗәдән югарырак булса, мондый хезмәткәрләргә база окладлы таләп ителә торган белем дәрәҗәсенә карап билгеләнә.»;

12 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12 нче таблица

Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең база окладлары һәм стимул бирү характерындагы түләүләр күләмнәре

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Күләм күрсәткеченең зурлыгы (уку елы башына карата тәрбияләнүчеләр саны), кеше* | База оклады, сум | Стимул бирү характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 – 20 | 25 000 | 3 000 |
| 2 | 21 – 40 | 27 000 | 3 000 |
| 3 | 41 – 60 | 31 000 | 4 000 |
| 4 | 61 – 80 | 32 000 | 5 000 |
| 5 | 81 – 100 | 35 000 | 6 000 |
| 6 | 101 – 140 | 37 000 | 7 000 |
| 7 | 141 – 180 | 40 000 | 8 000 |
| 8 | 181 – 220 | 43 000 | 9 000 |
| 9 | 221 – 280 | 44 000 | 10 000 |
| 10 | 281 – 320 | 45 000 | 11 000 |
| 11 | 321 – 360 | 45 000 | 12 000 |
| 12 | 361 һәм аннан да югарырак | 46 000 | 13 000 |

*Җайлаштырылган белем бирү программалары тормышка ашырыла торган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.

Туберкулез белән агуланган балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр контингенты 2 коэффициенты белән исәпкә алына»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Өстәмә белем бирү оешмаларында хезмәткәрләрнең хезмәт хакының база окладларын билгеләү

1. Өстәмә белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләренең хезмәт хакының база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | 1 айга база окладый күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персоналның һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Уку-укыту эшләре бүлеге секретаре | 15 279 | 15 552 | - |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт буенча инструктор | - | 16 142 | 18 362 |
| | Физик культура буенча инструктор | | | |
| | Музыка җитәкчесе | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Мөгаллим тренер | - | 16 149 | 18 382 |
| | Концертмейстер | | | |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | | | |
| | Оештыручы педагог | | | |
| | Социаль педагог | | | |
| | Инструктор-методист | - | - | 18 382 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Производство белеме бирү мастеры | - | 16 155 | 18 394 |
| | Педагог-психолог | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | Методист | - | - | |
| | Өстәмә белем бирү буенча өлкән педагог | | | |
| | Өлкән мөгаллим тренер | | | |
| | Өлкән инструктор-методист | | | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Мөгаллим (профессорлар һәм мөгаллимнәр составына кертелгән мөгаллим вазифасыннан башка) | - | 16 157 | 18 398 |
| | Физик тәрбия җитәкчесе | | | |
| | Өлкән методист | - | - | |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту һәм консультация бирү пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программалары тормышка ашырылган башка структур бүлекчәләр мөдире | - | - | 18 463 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Мәгариф программасы һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программасы тормышка ашырылган, аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | - | - | 18 526 |

2. Өстәмә белем бирү оешмаларында авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | 1 айга база окладың күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Икенче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Ветеринария фельдшеры | - | 16 855 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Үсемлекләрне саклау буенча агроном (урта квалификация) | | | |
| Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| | Агроном | - | - | 17 411 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Зоотехник<br>Ветеринария табибы | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | II категорияле агроном<br>II категорияле зоотехник<br>II категорияле ветеринария табибы | - | - | 17 466 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | I категорияле агроном<br>I категорияле зоотехник<br>I категорияле ветеринария табибы | - | - | 17 521 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Төп агроном<br>Төп зоотехник<br>Төп ветеринария табибы | - | - | 17 576 |
| Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Баш агроном | - | - | 18 302 |

3. Өстәмә белем бирү оешмаларында медицина хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 17 200 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы* | 18 900 |
| «Табиблар һәм провизорлар» вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 20 600 |
| *Вазифа оешмада өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташлары буйсынуда булганда билгеләнә. | | |

4. Өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында мәдәният хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Аккомпаниатор | 16 388 | 16 899 | 17 199 |
| Костюмнар бүлеге мөдире | | | |
| Мәдәни чаралар оештыручы | | | |
| «Төп звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Библиограф | 16 388 | 17 399 | 19 899 |
| Китапханәче | | | |
| Төп китапханәче | | | |
| Тавыш операторы | | | |
| Фондларны саклаучы | | | |
| Рәссам-скульптор | | | |
| Куючы рәссам | | | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | - | 18 599 | 21 199»; |
| Китапханә бүлеге (секторы) мөдире | | | |
| Кино һәм видеофильмнар прокаты бүлеге (пункты) мөдире | | | |
| Тавыш режиссеры | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Куючы режиссер | | | |
| Сәнгать җитәкчесе | | | |

15 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 нче таблица

Өстәмә белем бирү оешмалары җитәкчеләренең база окладлары һәм башкарыла торган эшләренең сыйфаты өчен стимул бирү характерындагы түләүләр күләмнәре

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Күләм күрсәткеченең зурлыгы (уку елы башына карата дәүләт биреме нигезендә укучылар саны), кеше | База оклады, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимул бирү характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 – 200 | 25 000 | 2 000 |
| 2 | 201 – 400 | 27 000 | 3 000 |
| 3 | 401 – 700 | 31 000 | 3 000 |
| 4 | 701 – 1 200 | 32 000 | 4 000 |
| 5 | 1 201 – 1 800 | 35 000 | 5 000 |
| 6 | 1 801 һәм аннан да югарырак | 37 000 | 6 000»; |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

1. Һөнәри белем бирү оешмаларында мәгариф хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Уку-укыту эшләре бүлеге секретаре | 15 279 | 15 552 | - |
| Икенче дәрәҗә уку-укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кече тәрбияче | 15 362 | 15 662 | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Мәгариф учреждениесе диспетчеры | - | 15 862 | 15 872 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт буенча инструктор | - | 16 142 | 18 362 |
| | Физик культура буенча инструктор | | | |
| | Музыка җитәкчесе | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Инструктор-методист | - | - | 18 382 |
| | Концертмейстер | - | 16 149 | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | Өстәмә белем бирү педагогы | - | | |
| | Оештыручы педагог | - | | |
| | Социаль педагог | - | | |
| | Мөгаллим тренер | - | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | - | 16 155 | 18 394 |
| | Производство белеме бирү мастеры | - | | |
| | Методист | - | - | |
| | Педагог-психолог | - | 16 155 | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Мөгаллим (профессорлар һәм мөгаллимнәр составына кертелгән мөгаллимнәр вазифаларыннан башка) | - | 16 157 | 18 398 |
| | Тормыш иминлеге нигезләре буенча оештыручы мөгаллим | - | | |
| | Физик тәрбия җитәкчесе | - | | |
| | Өлкән тәрбияче | - | - | |
| | Өлкән методист | - | - | |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә | - | - | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | эшләүче тьютордан тыш) | | | |
| | Укытучы | - | 16 157 | |
| | Педагог-китапханәче* | - | - | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе, гомуми белем бирү программасы һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программасы тормышка ашырыла торган башка структур бүлекчәләр, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати технологик тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләре тормышка ашырыла | - | - | 18 463 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | торган оешма мөдире (башлыгы) (икенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан башка) | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Белем бирү программасы һәм балаларга өстәмә белем бирә торган мәгариф программасы тормышка ашырыла торган аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы), башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесе (бүлекчәсе) кабинеты, лабораториясе, бүлеге, бүлекчәсе, секторы, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе, укыту хуҗалыгы һәм башка | - | - | 18 526 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | структур бүлекчәләре башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) (өченче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан башка) | | | |
| | Башлангыч һәм (яки) урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесенең (бүлекчәсенең) өлкән мастеры | - | 16 312 | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесенең (бүлекчәсенең) аерымланган структур бүлекчәсе башлыгы (мөдире, директор, җитәкчесе, идарәчесе) | - | - | 18 562 |

*Төп гомуми белем бирү мәгариф программалары һәм урта гомуми белем бирү мәгариф программалары тормышка ашырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары өчен

2. Һөнәри белем бирү оешмаларында мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазифа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Костюмнар бүлеге мөдире | 16 388 | 16 899 | 17 199 |
| «Төп звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Библиограф | 16 388 | 17 399 | 19 899 |
| Китапханәче | | | |
| Төп китапханәче | | | |
| Тавыш операторы | | | |
| Фондларны саклаучы | | | |
| Куючы рәссам | | | |
| Рәссам-скульптор | | | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | | | |
| Музей бүлеге (секторы) мөдире | - | 18 599 | 21 199 |
| Китапханә бүлеге (секторы) мөдире | | | |
| Кино һәм видеофильмнар прокаты бүлеге (пункты) мөдире | | | |
| Тавыш режиссеры | | | |
| Куючы режиссер | | | |
| Сәнгать җитәкчесе | | | |

3. һөнәри белем бирү оешмаларында медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| «Беренче дәрәҗә медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Авыруларны карау буенча кече шәфкать туташы | 15 279 |
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 17 200 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| | Медицина лабораторія технигы (фельдшер-лаборант) | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Фельдшер | 17 900 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы | 18 900 |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән башка) | 20 600 |
| «Учреждениеләрнең югары медицина һәм фармацевтика белемле структур бүлекчәләр җитәкчеләре (табиб-белгеч, провизор)» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлек (бүлек, бүлекчә, лаборатория, кабинет, отряд һ.б.) мөдире (стационарның хирургия профилендәге бүлеге мөдиреннән башка) | 23 400 |

4. Һөнәри белем бирү оешмаларында физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа исеме | 1 айга база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Беренче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы | 15 279 | - | - |
| Икенче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы-инструктор | 15 279 | - | - |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Физкультура-спорт оешмалары инструктор-методисты<br>Тренер | - | 16 149 | 18 382 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Физкультура-спорт оешмаларының өлкән инструктор-методисты<br>Спорт буенча өлкән мөгаллим тренер | - | 16 155 | 18 394 |
| Өченче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт җыелма командаларының спорт медицинасы буенча табибы | - | 16 212 | 18 412 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спорт җыелма командасының өлкән тренеры | - | 16 262 | 18 463 |
| Дүртенче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт җыелма командасының баш тренеры | - | 16 362 | 18 562 |

5. Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлегендә яки һөнәри стандартларда билгеләнгән дәрәҗәдән белеме түбән булган хезмәткәрләр вазифага алынган очракта, мондый хезмәткәрләргә база оклады таләп ителә торган белем дәрәҗәсенә карап билгеләнә.

6. Хезмәткәрләрнең белем дәрәҗәсе Җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазифаларының бердәм квалификация белешмәлегендә яки һөнәри стандартларда билгеләнгән дәрәҗәдән югарырак булса, мондый хезмәткәрләргә база окладлы таләп ителә торган белем дәрәҗәсенә карап билгеләнә.»;

17 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 нче таблица

Һөнәри белем бирү оешмалары җитәкчесенең хезмәте өчен түләү төркемен характерлый торган күләм күрсәткечләре

| Җитәкченең хезмәте өчен түләү төркеме | Дәүләт биреме нигезендә күләм күрсәткеченең зурлыгы (уку елы башына карата укучылар саны), кеше* | База окладлы, сум | Стимул бирү характерындагы түләүләр, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 0 – 500 | 29 000 | 5 000 |
| 2 | 501 – 900 | 31 000 | 5 000 |
| 3 | 901 –1 300 | 32 000 | 6 000 |
| 4 | 1 301 – 2 000 | 35 000 | 6 000 |
| 5 | 2 001 – аннан да югарырак | 37 000 | 6 000 |

*Физик культура һәм спорт өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы, спорт осталыгын һәм югары спорт осталыгын камилләштерү этапларында белем бирүче һөнәри белем бирү оешмалары (олимпия резервы училищесы) укучылары контингенты 3 коэффициент белән исәпкә алына»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының мәгариф оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Татарстан Республикасының мәгариф оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

1. Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларында эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 279 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 477 |
| «Икенче дәрәҗә эшчеләр гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 618 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 792 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 15 970 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 16 501 |

2. Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | 1 айга база окладары күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 279 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 477 |
| «Икенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 15 618 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 15 792 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 15 970 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 16 197 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 16 383 |
| «Өченче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 16 573 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 16 766 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 16 963 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 17 164 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 17 390 |
| «Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 18 302 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 18 502 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 18 702 |

3. Хезмәткәр вазифасының һәм һөнәренең эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифалары буенча һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителә.

4. Берьюлы ике урында, шулай ук эш вакыты тулы булмаган шартларда эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә йә башкарылган эшләр күләменә карап гамәлгә ашырыла. Төп вазифа буенча, шулай ук төп урыннан тыш башка урында эшләү тәртибендә биләнә торган вазифа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазифа буенча аерым билгеләнә.»;

IV бүлекнең 6 пунктындагы 6.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә премияләр түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме окладлар түләүгә каралган хезмәт өчен түләү фондының (хезмәт хакы ставкаларының, хезмәт окладларының), төп вазифа һәм төп эш урыны буенча хезмәткәрләргә стимул бирү характерындагы башка түләүләрнең кимендә 2 процентын тәшкил итә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы югары белем бирү буенча дәүләт мәгариф оешмалары һәм өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Югары белем бирә торган мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасы өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

<table>
<tr><th rowspan="2">Квалификация дәрәҗәсе</th><th rowspan="2">Вазифа исеме</th><th colspan="3">1 айга база оклады күләме, сум</th></tr>
<tr><th>төп гомуми белем, урта гомуми белем</th><th>квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем</th><th>бакалавр, белгеч яки магистр дипломы белән раслана торган югары белем</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td><td>4</td><td>5</td></tr>
<tr><td colspan="5">Административ хуҗалык һәм уку-укыту буенча ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме</td></tr>
<tr><td rowspan="3">Беренче квалификация дәрәҗәсе</td><td>Факультет диспетчеры</td><td rowspan="3">-</td><td>21 862</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Уку-укыту һәм методик эшләр буенча белгеч</td><td>-</td><td rowspan="2">22 662</td></tr>
<tr><td>Уку-укыту мастеры</td><td>21 862</td></tr>
<tr><td rowspan="3">Икенче квалификация дәрәҗәсе</td><td>Уку-укыту һәм методик эшләр буенча II категорияле белгеч</td><td rowspan="3">-</td><td>-</td><td>23 262</td></tr>
<tr><td>Факультетның өлкән диспетчеры</td><td>22 462</td><td>-</td></tr>
<tr><td>II категорияле уку-укыту мастеры</td><td>-</td><td>23 262</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Өченче квалификация дәрәҗәсе</td><td>Уку-укыту һәм методик эшләр буенча I категорияле белгеч</td><td rowspan="2">-</td><td rowspan="2">-</td><td rowspan="2">23 462</td></tr>
<tr><td>Тьютор</td></tr>
</table>

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | I категорияле уку-укыту мастеры | | | |
| Профессорлар һәм мөгаллимнәр составы һәм структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Профессорлар һәм мөгаллимнәр составы | | | | |
| Беренче квалифика-ция дәрәҗәсе | Ассистент | - | - | 30 062 |
| | Мөгаллим | | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән мөгаллим | | - | 30 102 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Доцент | | - | 35 662 |
| Дүртенче квалифика-ция дәрәҗәсе | Профессор | | - | 50 262 |
| Бишенче квалифика-ция дәрәҗәсе | Кафедра мөдире | | - | 50 662 |
| Алтынчы квалифика-ция дәрәҗәсе | Факультет деканы | | - | 51 062 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре | | | | |
